РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
АЛЬШЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘЛШИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

13.07.2023 ел № 1-72

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Әлши авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 28 декабрендәге 562-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Әлши авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл Советының 2018 елның 16 июлендәге 50-2 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Әлши авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган (12.05.2020 № 82-1, 19.08.2020 № 89-2, 20.10.2020 № 2-4, 15.09.2021 № 27-1, 11.10.2021 № 30-1, 08.04.2022 № 1-42, 18.07.2022 № 1-50, 11.08.2022 № 51-2 карарлары редакциясендә). Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (алга таба–Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 11 статьяда:

1 өлешнең 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча һәм федераль законнар нигезендә җирле үзидарә органнарын хәл итәргә хокуклы башка мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар кабул итү, шулай ук әлеге мәсьәләләр буенча муниципаль берәмлек (муниципаль берәмлек исеменнән) шартнамәләр, шул исәптән шәһәр округы торган инфраструктураны бергәләп үстерү өчен муниципальара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү;»;

1.2. 16.1статьяда:

2 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләр, шулай ук әлеге статьяның 6 - 8 пунктларында күрсәтелгән субсидияләр), шәхси эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр түбәндәгечә бирелә:

җирле бюджеттан- муниципаль берәмлек Советының җирле бюджет турындагы карары белән каралган очракларда муниципаль берәмлек Башкарма комитетының муниципаль хокукый актларында яисә ул вәкаләт биргән җирле үзидарә органнары актларында билгеләнгән тәртиптә, әлеге статьяның 2.1 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш»

6 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бюджет турындагы карарда, шул исәптән Россия Федерациясе Президенты, юридик затлар (муниципаль учреждениеләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләр, физик затлар тарафыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү өчен, шул исәптән конкурентлык

нигезендә бирелә торган субсидияләр рәвешендә, бюджет ассигнованиеләре күздә тотылырга мөмкин.

Субсидияләр рәвешендә грантлар әлеге пунктта күрсәтелгән грантлардан тыш, аларны бирү тәртибе Россия Федерациясе Президенты карары белән билгеләнгән грантлардан тыш, биреләләр :

җирле бюджеттан- әлеге статьяның 2 пунктында яисә 2.1 пунктында күрсәтелгән тәртип нигезендә.».

1.3. 16.1 статьясын түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.1. Муниципаль берәмлек Советының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен, субсидияләрне көйләүче муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән очракларда, әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән субсидияләр җирле бюджеттан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртипкә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексына ярашлы рәвештә җирле бюджет акчаларының Баш идарәчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының аның нигезендә кабул ителә торган карарларына ярашлы рәвештә бирелә.».

2. Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге Советының 2023 елның 9 мартындагы 1-65 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» карарын гамәлдән чыгарырга.

3. 1.2. һәм 1.3. пунктларыннан тыш, әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълумати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның 1.2. – 1.3. пунктлары 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Әлши авыл җирлеге башлыгы В.П. Сюрмин